# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы
Акбаш авыл җирлеге
Акбаш торак пунктында халык җыены нәтиҗәләре турында

**21.11.2020 ел** **№1**

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә, 2020 елның 21 ноябрендә узган гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: «2021 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлегенең Акбаш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 400 (дүрт йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм аны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрүгә сез ризамы:

1) Акбаш торак пунктындагы Мәктәп урамын асфальтлау;

2) Акбаш торак пунктында чишмә территориясен төзекләндерү (төзелеш материаллары һәм җиһазлар сатып алу; эскәмияләр сатып алу һәм урнаштыру; буяу; юл җәю; пьедесталны ремонтлау; килешү буенча эшләр өчен түләү).

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 329 кеше кертелгән, тавыш бирүдә 175 кеше катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

175 кеше «РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыенытүбәндәге карар кабул итте:

1. Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлеге Акбаш торак пунктында халык җыенын узган дип таныргa, халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә дип исәпләргә.

2. «2021 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлеге Акбаш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 400 (дүрт йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

1) Акбаш торак пунктындагы Мәктәп урамын асфальтлау;

2) Акбаш торак пунктында чишмә территориясен төзекләндерү (төзелеш материаллары һәм җиһазлар сатып алу; эскәмияләр сатып алу һәм урнаштыру; буяу; юл җәю; пьедесталны ремонтлау; килешү буенча эшләр өчен түләү) - карарын кабул ителгән дип санарга.

3. Акбаш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халык җыены нәтиҗәләрен халыкка игълан итәргә һәм Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында (http://jutaza.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Акбаш авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлар регистрына кертү өчен юлларга.

Халык җыенында рәислек итүче,
Ютазы муниципаль районы
Акбаш авыл җирлеге башлыгы Л.Р.Синагатуллина